| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БУРМЕТЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КИЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 15 «30» май 2022 ел

Сулыкларда кешеләрнең иминлеген тәэмин итү һәм үлемен булдырмау чаралары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә суда кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге территориясендә урнашкан сулыкларда куркынычсызлыкны саклау максатларында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Авыл җирлеге территориясендә рөхсәтсез коену урыннары булу сәбәпле:

1) кешеләр тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркыныч урыннарда халыкка су коенуны тыюлар билгеләргә;

2) рөхсәт ителмәгән коену урыннарында «Купаться запрещено», «Су коену тыела» язулы аншлаглар урнаштырырга.

2. Киекле авыл җирлеге территориясендәге мәктәп директорларына инструктажларны теркәү кенәгәләрендә укучылар һәм ата-аналар белән, су объектларында коену өчен җайлаштырылмаган урыннарда тәртип кагыйдәләре турындагы кануннар таләпләрен үтәү буенча инструктажлар үткәрүне тәкъдим итәргә.

3. ФАП мөдирләренә халык арасында судагы бәхетсезлек очракларында беренче медицина ярдәме күрсәтү буенча аңлату эшләрен оештырырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны җәмәгать урыннарында һәм интернет челтәрендәге рәсми сайтта мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Нурлат муниципаль районы
Киекле авыл җирлеге башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Ф.И. Сафина